Республика Татарстан

СОВЕТ ЧУКМАРЛИСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САРМАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ул. Советская, д. 41,с.Чукмарлы
423367
Телефон: 4-90-38

Татарстан Республикасы

САРМАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЧУКМАРЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Чукмарлы авылы, Совет урамы, 41 йорт,
423367
Телефон: 4-90-38

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«24» ноябрь 2020 ел № 12

2021 елга һәм 2022-2023 еллар план чорына Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Чукмарлы авыл җирлеген социаль-икътисадый үстерү фаразы турында

«2021 елга һәм 2022-2023 еллар план чорына Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Чукмарлы авыл җирлегенең социаль-икътисадый үсеш фаразы турында» мәгълүматны тыңлап фикер алышканнан соң, Сарман муниципаль районының Чукмарлы авыл җирлеге советы КАРАР ИТТЕ:

1. «2021 елга һәм 2022-2023 еллар план чорына Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Чукмарлы авыл җирлегенең социаль-икътисадый үсеш фаразы турында» мәгълүматны игътибарга алырга (1нче кушымта).

2. Сарман муниципаль районының Чукмарлы авыл җирлеге башкарма комитетына Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Чукмарлы авыл җирлегенең 2021 елга һәм 2022-2023 елларның план чорына социаль-икътисадый үсеш фаразын үтәүне тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Сарман муниципаль районының Чукмарлы авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Чукмарлы авыл җирлеге
Советы Рәисе И.Х.Хәдиуллин

1 нче кушымта

**2021 елга һәм 2022-2023 елларның план чорына**
**Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районыЧукмарлы авыл җирлегенең социаль-икътисадый үсеш фаразы**

| Күрсәткечнең исеме | Үлчәү берәмлеге | 2018 | 2019 | 2020 | 2021 | 2022 | 2023 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Хисап | Хисап | Бәя | Фараз | Фараз | Фараз |
| Халык саны | кеше | 449 | 450 | 450 | 455 | 460 | 460 |
| Алдагы елга үсеш темпы | % | 1 | 1 | 0 | 1 | 1 | 1 |
| Эре мөгезле терлекләр саны | баш | 390 | 390 | 400 | 400 | 400 | 400 |
| Алдагы елга үсеш темпы | % | 1 | 0 | 1 | 0 | 0 | 0 |
| Инвестицияләр | мең сум. | 3200 | 3400 | 3500 | 3600 | 3600 | 3600 |
| Алдагы елга үсеш темпы | % | 0 | 1 | 1 | 1 | 0 | 0 |
| Торак тапшыру | кв. м. | 60 | 0 | 100 | 100 | 100 | 100 |
| Алдагы елга үсеш темпы | % | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 |
| Хезмәт өчен түләү фонды | мең сум. | 1055,2 | 1068,9 | 1030,4 | 1009,8 | 1069,4 | 1071,5 |
| Алдагы елга үсеш темпы | % | 1 | 1 | -1 | -1 | 1 | 1 |
| Уртача айлык хезмәт хакы | сум. | 29311,1 | 29691,7 | 28622,2 | 28050,0 | 29705,6 | 29763,9 |
| Хезмәткәрләрнең исемлек буенча уртача саны | кеше | 3 | 3 | 3 | 3 | 3 | 3 |
| Эшмәкәрләр саны (КФХ)) | кеше | 10 | 10 | 10 | 12 | 12 | 12 |
| Эшсезләр саны | кеше | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 |

Чукмарлы авыл җирлеге хисапчысы: Мардонова З.Х.Мәрдәнова

**2021 елга һәм 2022-2023 елларның план чорына**
**Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы**
**Чукмарлы авыл җирлеге**
**социаль-икътисадый үсеш фаразына**
**аңлатма язуы**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Чукмарлы авыл җирлегенең социаль-икътисадый үсеше фаразына керем чыганакларын һәм бюджет чыгымнары статьяларын формалаштыру өчен кирәкле төп макроикътисади күрсәткечләрне үз эченә ала.

Сарман муниципаль районы Чукмарлы авыл җирлегенең 2021-2023 еллар чорына социаль-икътисадый үсеше фаразы Россия Икътисадый үсеш министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән 2021-2023 елларга Россия Федерациясе икътисады эшчәнлегенең сценар шартларының база варианты нигезендә эшләнде, Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлегенең 2020 елда көтелә торган нәтиҗәләрен һәм 2021-2023 елларда икътисад һәм социаль өлкә үсеше тенденцияләрен исәпкә алып, 2021-2023 елларга Россия Икътисадый үсеш министрлыгы тәкъдим иткән инфляция һәм дефлятор-индексларны кулланып эшләнде.

2020-2022 елларда «Urals» нефтенә бәяләрнең баррель өчен 43,3-46,5 АКШ доллар дәрәҗәсендә уртача динамикасы фаразлана.

2021 елда долларның уртача еллык курсы АКШ доллары өчен 70,8 сум, 2022 елда – 71,1 сум дәрәҗәсендә булыр дип фаразлана. 2023 елда, Россия Икътисадый үсеш министрлыгы фаразына караганда, доллар курсы АКШ доллары өчен 72,4 сум тәшкил итәчәк.

Чукмарлы авыл җирлеге өч торак пункттан тора: Чукмарлы, Нарат-Асты һәм Сәях авыллары.

Сарман муниципаль районыЧукмарлы авыл җирлегенең 2021 елга халык саны 455 кеше тәшкил итәчәк, 2022 елга-460 кеше, 2023 елга-465 кеше.

Авыл хуҗалыгын үстерү фаразы «АГРОСИЛА ГРУПП» ЯАҖ «Сарман» агрофирмасы ҖЧҖ, фермер һәм шәхси ярдәмче хуҗалыкларның булган потенциалын һәм үсеш тенденцияләрен, шулай ук «Развитие АПК» программасын гамәлгә ашыру буенча билгеләнгән чараларны исәпкә алып һәм «Шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерү» программасын гамәлгә ашыру буенча билгеләнгән чараларны исәпкә алып эшләнгән.

Хәзерге вакытта авыл җирлеге территориясендә «Сарман» агрофирмасы ҖЧҖ, «АГРОСИЛА ГРУПП» ЯАҖ һәм Кузнецов Ю.Н., Лабашов А.Н.,Семенова В.Д.,Миннуллин И.Х. крестьян-фермер хуҗалыклары эшчәнлеге алып барыла.

2020 елда авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү күләме 827,4 сумнан артык булачак. 2021 ел фаразы буенча продукция күләме 876,6 миллион сум, 2022 876,6 млн.сум, 2023 елда – 5% ка артачак һәм 948,5 млн. сум тәшкил итәчәк.

2020 елда төп капиталга инвестицияләр якынча 30000сум тәшкил итәчәк. 2021 елда 36000 сум күләмендә фаразлана, 2022-2023 елларда үсеш темпы 3,2-15% һәм 36000 һәм 370000 сум тәшкил итәчәк.

2021-2023 елларда 100 квадрат метр торак файдалануга тапшыру планлаштырыла.

2020 елда хезмәт хакы фонды 1030,4 мең сум тәшкил итәчәк.

2021 елга хезмәт хакы фондының фаразланган күрсәткече – 1,01 миллион сум, 2022 елда – 1,07 миллион сум, 2023 елда- 1,07 миллион сумнан артык.

Хезмәткәрләрнең уртача исемлек саны 3 кеше тәшкил итә.

Уртача айлык хезмәт хакы 2020 елда 28622,2 сум, 2021 елга ул 28050 сум, 2022 елда – 29705,6 сум, 2023 елда 29763,9 сум тәшкил итәчәк.

Эшмәкәрләр саны 2021 елга 12 кеше тәшкил итәчәк, 2022 елга-12 кеше, 2023 елга-12 кеше.